# КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге составына керүче Макаровка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 елның 12 ноябре № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 12 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Макаровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, һәрби хезмәттәге, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 7500 сумкүләмендә 2025 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, караптоту.

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 15 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 11 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 11 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге составына керүче Макаровка торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип таныргa.
2. « Түбән Кама муниципаль районының Макаровка авыл җирлеге Макаровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, һәрби хезмәттәге, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 7500 сумкүләмендә 2025 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, караптоту.

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Макаровка авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Макаровка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Кудряшов